| МИНИСТЕРСТВО ЗЕМЕЛЬНЫХ И ИМУЩЕСТВЕННЫХ ОТНОШЕНИЙ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ҖИРҺӘМ МӨЛКӘТ МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ МИНИСТРЛЫГЫ |
|---|---|---|
| **ПРИКАЗ** | | **БОЕРЫК** |
| 27.06.2019 | Казан ш. | № 309-пр |

**Журналистларны Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы каршында аккредитацияләү кагыйдәләрен раслау турында**

«Массакүләм мәгълүмат чаралары турында» 1991 елның 27 декабрендәге № 2124-1 Россия Федерациясе Законының 48 статьясы нигезендә б о е р а м:

1. Журналистларны Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы каршында аккредитацияләү кагыйдәләрен расларга (кушымта итеп бирелә).

2. Матбугат чаралары белән хезмәттәшлек итү һәм чараларны тормышка ашыру бүлеге мөдиренә (В.П.Строева) журналистларны Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы каршында аккредитацияләү кагыйдәләренең әлеге боерык белән расланган таләпләре үтәлешен тәэмин итәргә

3. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшерүдә тотуны үз өстемә алам.

**Министр**
**А.К.Хамаев**

Татарстан Республикасы
Җир һәм мөлкәт
мөнәсәбәтләре
министрлыгының
_27_.06_. 2019 №_309-пр_
карары белән расланды

Журналистларны Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы каршында аккредитацияләү
кагыйдәләре

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Кагыйдәләр «Массакүләм мәгълүмат чаралары турында» 1991 елның 27 декабрендәге № 2124-1 Россия Федерациясе Законының 48 статьясы нигезендә массакүләм мәгълүмат чаралары журналистларын Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы каршында аккредитацияләү (алга таба - аккредитация, Министрлык) процедурасын регламентлаштыра.

1.2. Аккредитация сроксыз нигездә гамәлгә ашырыла. Массакүләм мәгълүмат чарасы редакциясе теләге буенча аккредитацияләү конкрет редакция йөкләмәсен үтәү өчен яки аккредитацияләнгән журналистны ул булмаган вакытка алыштырып тору өчен билгеле бер вакытка да (вакытлы аккредитация) эшләнергә мөмкин.

## II. Аккредитация хокукы

2.1. Аккредитация хокукына, милек рәвеше һәм гамәлгә куючылар составына карамастан, барлык массакүләм мәгълүмат чаралары редакцияләре, шулай ук чит ил массакүләм мәгълүмат чаралары ия була ала. Чит ил массакүләм мәгълүмат чарасы журналистын аккредитацияләү өчен аның Россия Федерациясе Тышкы эшләр министрлыгы каршында аккредитация узган булуы кирәк.

## III. Аккредитацияләү тәртибе

3.1. Министрлыкка массакүләм мәгълүмат чарасы редакциясе җитәкчесе имзасы куелган аккредитацияләү гаризасы Министрлык тарафыннан әлеге гаризаның алыну фактын, көнен һәм вакытын раслау мөмкин булган теләсә кайсы ысул белән бирелә.

3.2. Гаризада журналистның фамилиясе, исеме, әтисенең исеме (булганда),

аның вазыйфасы, эш һәм кәрәзле телефоннары номеры, электрон почтасы адресы, массакүләм мәгълүмат чарасының тулы атамасы, массакүләм мәгълүмат чарасын теркәү турында таныклык датасы һәм номеры күрсәтелә.

Вакытлы аккредитация гаризасында шулай ук редакция йөкләмәсе һәм аны үтәү чоры күрсәтелә, аккредитация узган журналистның вакытлыча булмый торуы сәбәпле башкага алыштыру очрагында – әлеге затны алыштыручы журналистның фамилиясе, исеме, әтисенең исеме (булганда) һәм аны аккредитацияләү срогы күрсәтелә.

Чит ил массакүләм мәгълүмат чаралары журналистларын аккредитацияләгәндә өстәмә рәвештә Россия Федерациясе Тышкы эшләр министрлыгы каршында аккредитация узганлыкны раслаучы документларның күчермәләре дә бирелә.

3.3. Әлеге Кагыйдәләрнең 3.2 пункты таләпләренә туры килми торган гаризалар каралмый.

3.4. Аккредитацияләү (аккредитацияләүдән баш тарту) турындагы карар Татарстан Республикасы җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министры (аның вазыйфаларын башкаручы зат) (алга таба – министр) тарафыннан гариза кергәннән соң ике эш көненнән дә соңга калмыйча кабул ителә. Мондый карар, министр боерыгы чыкканнан соң икенче эш көненнән дә соңга калмыйча, гариза юллаган массакүләм мәгълүмат чарасы редакциясенә, аның редакция тарафыннан кабул ителү фактын, көнен һәм вакытын раслаучы теләсә кайсы ысул белән җиткерелә.

3.5. Массакүләм мәгълүмат чарасы махсуслашкан характерда (реклама тарату, эротик басмалар) булган очракта аккредитацияләү башкарылмый.

3.6. Гаризаны карау, министрның аккредитацияләү (аккредитацияләүдән баш тарту) турындагы боерыгы проектын әзерләү, шулай ук кабул ителгән карар турында массакүләм мәгълүмат чарасы редакциясенә хәбәр итү Министрлыкның ММЧ белән хезмәттәшлек итү һәм чараларны тормышка ашыру бүлегенең әйдәп баручы белгече тарафыннан әлеге Кагыйдәләрдә билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда гамәлгә ашырыла.

## IV. Аккредитацияләнгән журналистларның хокуклары һәм бурычлары

4.1. Аккредитацияләнгән журналистлар түбәндәгеләргә хокуклы:

чараларда катнашырга;

чара турында Министрлыкта булган рәсми документларның күчермәләрен (көн тәртибе, пресс-релизлар, мәгълүмати-белешмәлек, статистик, аналитик һәм башка материаллар) алырга;

бастырып чыгару өчен каралган мәгълүмати-белешмәлек материаллары белән танышырга;

Россия Федерациясе законнарында каралган башка хокуклар.

4.2. Аккредитацияләнгән журналистларның бурычлары:

чара регламентын сакларга һәм, әгәр дә ул махсус массакүләм мәгълүмат чаралары өчен планлаштырылмаган булса, аның барышына катышмаска;

чарада катнашучылар эшчәнлегенә комачауламаска;

үз басмаларында (эфир эшчәнлегендә) Министрлыктан бирелгән пресс-релизларны, мәгълүмати-белешмәлек, статистик, аналитик һәм башка метериалларны файдаланганда мәгълүмат чыганагына сылтама бирергә;

үз профессиональ эшчәнлеген гамәлгә ашырганда Министрлык эшчәнлеге турында дөреслеккә туры килми торган мәгълүматлар таратмаска.